# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

2025 елның 27 ноябре № 1

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы "Дәүләт хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законның 45, 69 маддәләренә, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Законының 35 маддәсенә нигезләнеп, 2025 елның 26 ноябрендә узган гражданнар җыенының "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы сез, I группа инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучылардан, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез ризамы:

1) Рантамак торак пунктында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

2) Рантамак торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) Рантамак авылында хуҗасыз хуҗалыкларны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу

4) Рантамак авылында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

5) Рантамак авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

6) Беларустракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

7) трактор өчен асылмалы җайланмалар сатып алу.

8) кое тирәсен койма белән әйләндереп алу

ЭЙЕ ЮК ?"

мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 103 катнашучы кертелгән, җыенда катнашучылар саны 58.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышы түбәндәгечә бүленде: «хуплау» позициясе өчен гражданнар Җыенының 58 катнашучысы тавыш бирде; «каршы» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Рангазар торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Рантамак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

кешедән, I группа инвалидларыннан, ялгыз карт гражданнардан (80 яшькә җиткән), көндезге уку формасында белем алучы студентлардан, вакытлы хәрби хезмәт узучы гражданнардан, контракт буенча хәрби хезмәт узучылардан, мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) Рантамак торак пунктында кышкы вакытта җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү) ;

2) Рантамак торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергияне саклый торган яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

3) Рантамак авылында хуҗасыз хуҗалыкларны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу

4) Рантамак авылында җәйге вакытта территорияне чабу (шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

5) Рантамак авыл эчендәге юлларны ремонтлау (транспорт хезмәтләре күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү)

6) Беларустракторын тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, йөртүчегә хезмәт хакы түләү);

7) трактор өчен асылмалы җайланмалар сатып алу.

8) кое тирәсен койма белән әйләндереп алу

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Рангазар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://sarmanovo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Рангазар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы Р.Н.Кыямов

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021601313470
Совет Рангазарского сельского поселения
Рангазар авыл җирлеге Советы
ИНН 1636001280